ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, , 423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы,
37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№3** **8 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәшбүләк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. , 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. 2019 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Көрәшбүләк авылы, Совет урамы, 9А йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Көрәшбүләк авылы гражданнары җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

"Сез 2020 елда Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Көрәшбүләк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итүгә чакырылучылардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Көрәшбүләк авылына керү юлын асфальт түшәп ремонтлауга (аны булдыруга, асфальт түшәүгә, эшләргә килешү буенча түләүгә) ;

« ӘЙЕ» “ЮК".

3. Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны ул кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында www.yutaza.tatar.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

“Бәйрәкәтамак авыл җирлеге”

муниципаль берәмлеге башлыгы З.М. Әгълиева